Юбилей: [Рәшит Бәшәрнен 75 яшьлек юбилеена багышланган] // Казан утлары. – 2025. - № 2. – Б. 191.

**ЮБИЛЕЙ**

Чаллыда татар әдәбияты көннәре кысаларында язучы. А.Алиш. Ш.Галиев исемендәге әдәби премияләр лауреаты Рәшит Бәшәрнен 75 яшьлек юбилеена багышланган тантаналы чаралар булып узды. Чаллы Тагар дәүләт драма театрының сәнгать җитәкчесе Олег Кинҗәгулов язучының тормышына һәм иҗатына багышланган театраль тамаша әзерләде. Юбилярны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Винер Харисов, шагыйрьнең Казаннан кайткан һәм шәһәрдә яшәп иҗат итүче бер төркем каләмдәшләре, мәдәният, сәнгать әһелләре котлады. Сәхнәдән Рәшит Бәшәрнең әсәрләрен укыдылар. Алар жыр. биюләр белән үрелеп барды. «Агадир» цирк студиясе чыгышы да бәйрәмгә ямь өстәде.